РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ**
**ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ**
**ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**24.05.2023 ел** **Чистай шәһәре** **№22/3**

«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге
милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген
кече һәм урта эшкуарлык субъектларына,
шәхси эшмәкәрләр булмаган физик затларга
һәм махсус салым режимын кулланучыларга
биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен
билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген
формалаштыру, алып бару һәм муниципаль
милек исемлеген бастырып чыгару тәртибен
раслау турында» 2019 елның 30 апрелендәге
34/5 номерлы Чистай шәһәр Советы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы

**Карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, шәхси эшмәкәрләр булмаган физик затларга һәм махсус салым режимын кулланучыларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм муниципаль милек исемлеген бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2019 елның 30 апрелендәге 34/5 номерлы (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2020елның 15 декабрендәге 4/6

номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Чистай шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

карарның 1 нче Кушымтасында:

2.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Исемлеккә өченче зат хокукларыннан азат булган биналар (корылмалар), торак булмаган биналар (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының милек хокукларыннан тыш) кертелә, шулай ук корылмалар, җиһазлар, махсуслаштырылган транспорт чаралары (үзйөрешле машиналар), башка күчеп йөрүче милек кертелергә мөмкин».

2. Әлеге карарны “Чистай хәбәрләре” газетасында, яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов